**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4947**
**27.09.2019**

Яр Чаллы шәһәре территориясендә «Җылыту – 2019» янгын-профилактика операциясе үткәрү турында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре территориясендә көзге-кышкы чорда «Җылыту – 2019» янгын-профилактика операциясе үткәрергә.

2. Тәкъдим итәргә:

1) идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләренә, торак кооперативларына һәм башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына «Җылыту – 2019» профилактика операциясен үткәрү чорында түбәндәгеләрне оештыруны:

- күп фатирлы йортларның торак милекчеләренең янгынга каршы чаралар оештыру мәсьәләсе буенча гомуми җыелышын үткәрү;
- гражданнарны яшәү урыны буенча янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү, шул исәптән янгынга каршы чаралар үткәрү турында мәгълүмат әзерләү һәм тарату;
- халык арасында янгынга каршы тематикага агитация һәм пропаганда материаллары әзерләү һәм тарату;
- электр челтәрләренең, җылылык системасының, җылылык җитештерүче агрегатларның, электр җылыту приборларының һәм башка электр приборларының, электр җайланмаларының төзеклеген тикшерү;
- күп катлы торак йортларда янгыннан саклау системаларының торышын (эвакуация баскычлары, балкондагы ябык люклар йозакларының ачкычлары булу) тикшерү, подвал һәм чорма бүлмәләрен яна торган чүпләрдән чистарту эшләре үткәрү, шулай ук, йортлар чормасының һәм

подвалларының ябык люкларын һәм ишекләрен карап тотуны контрольдә тоту;

2) Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ баш идарәсе күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр идарәсенең Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенә Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе, Башкарма комитетның районнар хакимиятләре белән берлектә:

- профилактика төркемнәренә социаль яраклашмаган гражданнарның, аерым алганда, наркотик чаралар яки спиртлы эчемлекләр артык күп кулланучы затларның, имин булмаган күп балалы гаиләләрнең, өлкән яшьтәге гражданнарның, авыр тормыш шартларында калган затларның яшәү урыннарын тикшерүне дәвам итәргә һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозу очракларын бетерү буенча чаралар күрергә;

- «Җылыту – 2019» профилактика операциясе үткәрү буенча янынга каршы чараларның план-графигын эшләргә.

3. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре территориясендә «Торак – 2019» профилактика операциясе үткәрү турында» 2019 елның 4 февралендәге 512 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин